Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Чарлы авыл җирлеге Советы

# КАРАР

31.08.2019 ел № 11

Чарлы авыл җирлеге Советы 2014 елның 31 нче январе 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Кукмара районы прокурорының 2019 елның 14 июнендәге 02-01-22-2018 номерлы, ачыкланган коррупцион факторны бетерү максатыннан, норматив хокукый актны үзгәртү турындагы таләбен карап, Чарлы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

Чарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән расланган (Чарлы авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 декабрендәге 30 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 11 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге 2 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 статьяның 11 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Чарлы авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту Кагыйдәләре белән территориаль зоналарны яисә аларның өлешләрен өстәмә юнәлешләр буенча куллануга аерым шәһәр төзелеше таләпләре билгеләнә:».

Чарлы авыл жирлеге башлыгы Э.Н.Козлов